Укытучы - боек исем. Мордовия татар теле укытучыларыбыз бу исемне горур йортә. Октябрь аенын беренче коннәрендә регионыбызнын һәрбер белем бирv учагында, районында, башкалабызда Укытучылар конен зурлап vткәрделәр.
2025 елнын 3 октябрендә Ләмберә районнын «Алмаз» мәдәният vзәгендә, Укытучылар коне алдыннан, районнын ин яхшы педагогларын хормәтләделәр.   Югары педагогик осталыгы, белем һәм тәрбия бирvдә ирешкән унышлары очен Пензятка урта гомуми белем бирv мәктәбенен татар теле һәм әдәбияты укытучысы Юмаева Рауза Мукаддәс кызын «РФ мәгариф олкәсендә мактаулы хезмәткәр» исеме бирелде.

Олы педагогик хезмәте РФ Мәгариф министрлыгынын Мактау грамотасы белән Атюрьевонын икенче урта белем бирv мәктәбе директоры урынбасары Эльвира Хәйдар кызы Совешова бvләкләнде.
Мордовия Главасы Артём Здунов Указы нигезендә югары педагогик осталыгы һәм мәгарифкә зур олеш керткәне очен Диплом һәм акчалата премия белән Кадошкино районы Большие Поляны топ гомуми белем бирv мәктәбе татар теле укытучысы Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева һәм Ләмберә районы Татар Тавла топ гомуми белем бирv мәктәбенен татар теле һәм әдәбияты укытучысы Альфия Фатих кызы Муртазина бvләкләнделәр.

Барыгызга да исәнлек-саулык, кvнел кvтәренкелеге, зур унышлар, бетмәс-токәнмәс энергия, эшегездә яна vрләр яулавыгызны телибез!